


9 Май - хәтер, горурлык һәм Рәхмәт коне. Без Боек Ватан сугышы фронтларында сугышкан һәм тылда хезмәт иткән, жинvне кон саен якынайткан кешеләрне искә алабыз. Бу бәйрәм буыннарны берләштерә, батырлык, фидакарьлек һәм тынычлык бәясен искә тошерә.
Жинv коне Россия очен vзенчәлекле бәйрәм. Россия һәрвакыт ветераннарнын батырлыгы белән горурланачак. Мордовиялеләрнен дә һәр буыны жинvчеләрнен олы батырлыгын хәтерлиләр, илебез иминлеге очен һәлак булган солдатларны һәм хәзерге вакытта исән булган ветераннарны хөрмәтлибез, кvпмилләтле халкыбыз батырлыгына сокланабыз. Совет солдатларынын батырлыгы, фидакарьлеге һәм ныклыгы нәтижәсендә без тыныч тормышта яшибез, эшлибез, ижат итәбез, киләчәккә планнар корабыз һәм иртәгәсе кон турында зур ышаныч белән уйлый алабыз. Кадерле Боек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, хөрмәтле Мордовиялеләр! Сезне барыбыз очен дә изге һәм боек бәйрәм - Боек Ватан сугышында Жинvнен 80 еллыгы белән котлыйбыз!
Жинv, безнен тыныч тормышыбыз очен рәхмәт сезгә, кадерле сугыш ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, һәлак булган фронтовикларнын тол хатыннары һәм балалары. Сезгә сәламәтлек һәм озын гомер, гаиләләрегезгә иминлек һәм бәхет, тыныч һәм якты коннәр насыйп булсын!